СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.01.2026 № 1/вн-3

На № ________ от ____________

# КАРАР

**«Тукай муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2017 елның 29 маендагы 15/6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 һәм 39.15 статьяларына һәм «Геодезия, картография һәм пространство белешмәләре турында» Федераль законның 18.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 317-ФЗ номерлы Федераль законга, «Пространство белешмәләренең милли системасы» бердәм цифрлы платформасы» федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 07 июнендәге 1040 номерлы карарына, Тукай муниципаль районы уставына таянып, муниципаль берәмлек Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2017 елның 29 маендагы 15/6 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 3.43 пунктчасын өстәргә:

«3.43. Палата үз вәкаләтләрен тәэмин итү өчен, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын, шулай ук пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын файдаланырга хокуклы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары,
Совет Рәисе урынбасары

Р.И.Закиров